**«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»**

**ПАЛАТА ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»**

**ҖИР һӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ**

---

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**2022 елның «_31_» феврале** **№109**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
территориясендә муниципаль
җир контролен гамәлгә ашыру буенча
административ регламентның үз көчен
югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә керүгә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «Муниципаль җир контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 20 октябрендәге 10/7 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә

1. Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламенты раслау турында» 2019 елның 27 июнендәге 612 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентын (Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының 2019 елның 17 декабрендәге 1352 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге боерыкны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы" нда (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында www.chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче М.Ю.Исхакова